**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «02» апреленнән № 90

## Макулатура һәм полиэтилен җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының нигезләмәсен раслау турында

Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларның экологик торышын яхшырту, ишегалларын һәм урамнарны чистарту максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымтада бирелгән макулатура һәм полиэтилен җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының нигезләмәсен расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына конкурста җиңүчеләрне бүләкләү өчен 22 000 (егерме ике мең) сум акча бүлеп бирергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «02» апрелендәге
90 номерлы карары белән
расланган

# Макулатура һәм полиэтилен җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» конкурсының НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Макулатура һәм полиэтилен җыю буенча муниципаль конкурс (алга таба-Конкурс) үткәрү турында әлеге нигезләмә аны оештыру һәм үткәрү максатларын, бурычларын, тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Конкурс Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән.

## 2. Максатлар һәм бурычлар

2.1. Конкурс Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларының ишегалларын һәм урамнарын макулатура һәм полиэтиленнан чистарту максаты белән үткәрелә.

2.2. Конкурсның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

муниципаль бюджет белем бирү учреждениеләре (алга таба - МБГБУ) укучыларын туган авылны экологик чистарту буенча гамәли эшчәнлеккә җәлеп итү;

яшь буында әйләнә-тирә мохитнең чисталыгы өчен җаваплылык хисе формалаштыру;

район халкы арасында культура дәрәҗәсен күтәрү;

икенчел чималны рациональ куллану.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениеләре укучылары.

## 4. Конкурсны үткәрү тәртибе һәм сроклары

4.1. Конкурсны үткәрү вакыты 2025 елның 2 апреленнән 2025 елның 31 маена кадәр

4.2. Макулатура, полиэтилен җыю Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучылары тарафыннан башкарыла.

4.3.
Картон һәм кәгазь (газета, А4, журналлар) җыю аерым башкарыла.

4.4. Полиэтилен җыю аерым чүп-чар өчен пластик капчыкларга башкарыла.

4.5. Макулатура, полиэтилен массасын үлчәү икенчел чимал кабул итү пунктлары башкара.

4.7. Макулатура һәм полиэтиленны илтеп тапшыруны мәгариф оешмалары башкара.

## 5. Конкурста катнашучыларны бүләкләү

Конкурста җиңүчеләр (сыйныф) конкурста катнашучы сыйныф укучылары исеменә, Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү учреждениеләре укучылары тарафыннан икенчел чималны кабул итү пунктларына тапшырылган икенчел чимал күләме турында документлар нигезендә билгеләнә. Урыннар 500 килограммнан да ким булмаган икенчел чимал җыйган һәм тапшырган сыйныфка бирелә.

1 урын - 10000 сум

2 урын - 7000 сум

3 урын - 5000 сум